# Г.ИБРАҺИМОВНЫҢ ТАТАР ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЕН ФОРМАЛАШТЫРУ ҺӘМ ҮСТЕРҮДӘГЕ РОЛЕ

## (1910 еллар тәнкыйте мисалында)


### Аннотация

В данной работе рассматривается литературно-критическая деятельность Г.Ибрагимова. Он является одним из основоположников татарской литературной критики, которая начала формироваться в началеXX века, авторитетной и влиятельной личностью, известной в литературных кругах широтой кругозора и глубиной теоретической подготовки. Исследуя в своих научных трудах различные общетеоретические проблемы литературной критики, подвергая анализу творчества отдельных татарских писателей, он создал собственную литературно-эстетическую концепцию, способствующую выявлению критериев и научных основ оценки литературного процесса.


Киңкырлы талант иясе Г.Ибраһимовның татар әдәби тәнкыйте тарихында да кабатланмас үз урыны бар. Ул бу иҗат төре белән әдәби тәнкыйтьнең, эзләнүләр чоры үтеп, камилләшү-җитди сыйфади үзгәрешләр кичерә башлаган 1910-елларында шөгыльләнә башлый һәм тиз арада киң карашлы, теоретик әзерлекле, киң колачлы, талантлы һәм үзенчәлекле тәнкыйтьче буларак танылa. Күренекле галим тәнкыйди эшчәнлеген ике юнәлештә алып бара:1) әдәби тәнкыйтьнең поэтикасы һәм тарихы мәсьәләләре;2) әдәбият мәйданында урын алган әдәби әсәрләргә чорның гыйльми-нәзари, әдби-эстетик, әхлакый-фәлсәфи фикерләре ирешкән казанышлары ноктасыннан бәя бирү, үз заманының әдәби процесс үзенчәлекләрен ачу.

Г.Ибраһимовның татар әдәби тәнкыйте тарихында тоткан урыны, тәнкыйди эшчәнлеге һәм аның хасиятләре әдәбиятчы галимнәр тарафыннан мәгълүм дәрәҗәдә яктыртылган. XX гасыр башында татар дөньясында, ниһаять, әдәби тәнкыйтьнең фән буларак мәйданга килүе Г.Ибраһимовның

исеме белән дә бәйләп карала. Аның “Татар шагыйрьләре” китабына язылган рецензиясендә Г.Баттал болай ди: ”Галимҗан әфәнденең бу әсәре – чын тәнкыйть. Әдәбиятыбыз мондый тәнкыйтьләргә күптән мохтаҗ иде. Без, мондый әсәрләрне күргәч, әдәбиятыбыз җитди юлга кереп бара дип шатланабыз һәм Галимҗан әфәнденең тәнкыйть гыйлемендә алга таба бик зур адым атлаганын күрәбез”(1, 154). Татар әдәби тәнкыйте фәненең “остазы” булган профессиональ тәнкыйтьче Җ.Вәлиди тәнкыйть һәм әдәбиятта “мөтәхассыйс (белгеч) исемен алган яки алырга таба юл тоткан кешеләр”(2, 316) - “икенче буын мөхәррирләр” арасында Г.Ибраһимовны атый. Әлбәттә, бу замандашы тарафыннан тәнкыйтьчегә бирелгән югары бәя була.

1917 елгы Октябрь борылышыннан соң Г.Ибраһимовның әдәби тәнкыйть өлкәсендәге хезмәтенә Г.Сәгъди, М.Гайнуллин, М.Хәсәнов, М.Мәһдиев, Р.Мөхәммәдиев, Э.Галиева, Д.Заһидуллина һ.б. галимнәр игътибар итәләр. Дөрес, аерым бер эзләнүләрдә Ибраһимовның тәнкыйди фикерләре белән гыйльми-теоретик күзаллаулары, фәлсәфи-эстетик карашлары, кайбер очракларда публицистик эшчәнлеге тыгыз бәйләнештә карала. Бу хосусият әлеге тармакларның үзара тыгыз мөнәсәбәттә яшәүләреннән килә.

Әдәби тәнкыйть поэтикасына караган төшенчәләр, әсәрне бәяләү кагыйдәләре һәм алымнары, критерийлары, мәгълүм булганча, җанлы әдәби тәнкыйди хәрәкәт белән тыгыз бәйләнештә барлыкка килә һәм үсеш-үзгәреш кичерә. XX гасыр башында әдәби тәнкыйть яңа әдәбиятны, аның аерым берәмлекләрен аңлау-бәяләүнең кануннарын, фәнни нигезләрен ачыклый торган эстетик концепцияләр эзләү юлына чыга, ягъни ул әдәби-мәдәни мәйданга килгән һәрбер яңа фән кебек , иң беренче нәүбәттә, үз предметын, өйрәнү һәм бәяләү объектын ачыклау, үз билгеләнү хокукы, иҗтимагый вазифасы һәм функцияләре, әдәби барыштагы урыны, тәнкыйть этикасы, жанрлар системасы кебек мәсьәләләрне хәл итәргә алына.

Милли, әдәби-мәдәни күтәрелештә әһәмиятле роль уйнаган Шәрекъ һәм Гареб мәдәниятләренең уңай йогынтысы, хәтта бу ике культурологик ориентирның үзара бәхәсе әдәби тәнкыйтьнең мөһим теоретик мәсьәләләрен хәл иткәндә дә сиземләнә. Г.Ибраһимов, Ф.Әмирхан, Г.Тукай, Г.Баттал, М.Укмасилар тәнкыйди эшчәнлегендә үзе латин, борынгы грек цивилизациясе тәэсирендә калыплашкан Аурупа-рус әдәбият белеменең тәэсире зур булса, ә Р.Фәхретдин, Г.Сәгъди һ.б.лар төрки-татар дөньясы озак гасырлар тыгыз бәйләнештә яшәгән, әдәп-әхлак, белем алмашкан Шәрекъ мәдәниятенә таяналар. Татар галимнәре тарафыннан, мөмкин булганда, милли әдәбият белеменең, шул исәптән әдәби тәнкыйтьнең аерым терминнарын татарча эшләү теләге белдерелсә дә, ике мәдәниятнең ирешкән фәнни казанышларыннан башка бу мәсьәләне чишү мөмкин түгеллеге таныла. Бу хәрәкәтнең үзәгендә Г.Ибраһимов та кайный.

Г.Ибраһимов әдәби тәнкыйть фәне турындагы нәзари эзләнүләрен **“Әдәбият кануннары”** (1919) дигән хезмәтендә бер бүлекчәгә туплап урнаштыра. Билгеле булганча, аның беренче басмасы “Әдәбият дәресләре” исеме астында 1916 елда Казанда “Сабах” матбагасында дөнья күрә. Иң беренче нәүбәттә, әлеге методик әсбапта галимнең әдәби тәнкыйтьне фәнни нигезгә утырту омтылышын билгеләргә кирәк. Бу еллар тәнкыйди рухи мирасын актарганда, әдәби иҗатның бу төренә атама булып ике термин: **тәнкыйть** һәм **интикад**ның фәнни кулланылышта йөрүе күзәтелә. Г.Ибраһимовның аерым мәкалә-язмаларында интикад кулланылса да, тәнкыйть терминына өстенлек бирелә. Галим тәнкыйть сүзенең килеп чыгышы, мәгънәсе, фәнни һәм гамәли әйләнешкә керүе, аның тамырдаш, мәгънәдәш сүзләре турында уйлана : “Тәнкыйть сүзе “нәкыд” матдәсеннән алынган. Лөгать мәгънәсе акчаның чынын сахтәсеннән (ялганыннан) аеру димәктер” (3, 106).

Әдәби тәнкыйтьнең предметы, аның шартлары һ.б. гыйльми-нәзари төшенчәләрне шәрехләүдә Г.Ибраһимов, алда әйтелгәнчә, Аурупа-рус әдәбият белеме ирешкән казанышларга таяна. Мәсәлән, ул тәнкыйтьне

мантыйкый дәлилләр белән эш итүне һәм исбатлауны таләп иткән **мөхакәмә**нең бер төре итеп карый һәм алга таба тәнкыйтьнең теоретик мәсьәләләре аның тарафыннан шушы позициядән чыгып аңлатыла. Әдип моңа кадәр практик кулланылышта булган әдәби тәнкыйтьнең шартлары, таләпләре терминнары урынына кагыйдәләр, кануннар дигән төшенчәләргә мөрәҗәгать итә. Әдәби әсәргә бәя бирүнең үлчәмнәре турында сүз алып барып, **"мизан"** төшенчәсен фәнни әйләнешкә кертеп җибәрә: "Бер әсәрне яки бер язучының барлык әсәрләрен тикшереп, аларга кыйммәт куйганда, мөнәкъкыйднең шулардагы җитешкән яки җитешмәгән якларны билгеләүдә үзенең рәһбәр(юл күрсәтүче, таяныч) ителгән шул канун вә нәзарияләре "тәнкыйтьнең мизаны" – яки критериум дип атыйлар"(3, 106).

Г. Ибраһимов китапның кайсы өлкәгә, нинди жанрда язылуына карап, аны бәяләү мизаннарының да төрле булуын әйтеп чыга, аларны бер – берсеннән аерып куя. Мәсәлән, дәрес китабы белән әдәби әсәрләрне бәяләүдә бер төрле кануннар һәм нәзарияләргә таянуны кире кага. Автор тарафыннан "тикшерелгән әсәрнең эч йөзен, маһиятен(асылын) ачып бирү, әсәр теле, өслүбе, план вә мөндәриҗәсе(эчтәлеге) төп уйны ачып җитә алып – алмавы, хәяткә мөнәсәбәте" мәгълүм мизаннар ярдәмендә бәяләнергә тиешле яклар буларак аерып чыгарыла. Бәя-шәрехләүнең объективлыгын, берьяклы гына булмавын күздә тотып, тәнкыйтьне "ике йөзле хәнҗәргә тиңли". "Тәнкыйть ике йөзле үткен хәнҗәр булырга тиеш. Бу хәнҗәрнең бер ягы әсәрнең эчендәге җәүһәрләрне казып чыгарса, икенче ягы аның чүбекләрен табып күрсәтү"(3, 107).

"Әдәбият кануннары"нда әдәби тәнкыйтьнең төрләрен аерып чыгару, аларның үзенчәлекләрен билгеләү юнәлешендә дә тәнкыйтьченең карашлары урын алган. Әдәби тәнкыйтьнең әдәби әсәргә рекомендация бирү һәм әдәби әсәрнең "уңай" һәм "кире," "җитешкән вә җитешмәгән" якларына бәя бирү вазифасы Г.Ибраһимовка аның ике: **"иҗаби"(уңай)** һәм **"сәлби"(кире)** төрләрен күрсәтүгә юл ача. "Әсәрнең яхшы ягын күрсәткән тәнкыйтьләр

**иҗаби тәнкыйть** дип, җитешмәгәнен күрсәткәннәре **сәлби тәнкыйть** дип атала”(3, 107).  Дөрес, бередә кире тәнкыйтьнең әдипкә ярдәм итү, әсәрнең кимчелекле якларын бетерүдә юл күрсәтү сыйфаты калкытып куела: “Сәлби тәнкыйтьләр әсәрнең җитешмәгән якларын күрсәтү белән язучының үзен дә, башкаларны да шул хатадан, шул кимчелектән сакланырга юл эзләргә, шулай итеп төзәлүгә сәбәп булалар”(3, 107).  Г. Ибраһимов иҗаби тәнкыйтьнең ике функциясен калкытып куя: 1) халык тарафыннан илтифат ителми яткан яшь талантларның әсәрләрен тикшереп, шулардагы яхшы якларны күрсәтү, шул юл белән аларны дөньяга таныту, 2) дөньяга чыгып та, халык тарафыннан кирәгенчә тәкъдир ителмичә яткан әдәби әсәрнең “төбенә салынган тирән вә кыйммәтле җәүһәрне” укучыга ачып бирү.

. Әдәби тәнкыйтьнең жанр ягыннан үсү, баю чоры  XX гасыр башларына туры килә. Г.Ибраһимов -  әдәби тәнкыйтьнең жанрларын булдыру, аның сыйфатларын ачыклау юнәлешендә дә кызыклы фикерләр белән чыгыш ясаган галим. Г. Ибраһимов **рецензия**, **рәддия** һәм **мәкаләне** әдәби тәнкыйтьнең жанрлары буларак карый. Ул рецензиягә түбәндәге билгеләмәне бирә: “Мәйданга чыккан бер әсәр, тыңланган концерт, күрелгән спектакль хакында вакытлы матбугатта, дәлилләр белән исбатка керешелмичә,  кыска рәвештә тәэсир вә мөляхәзәне(фикер йөртүне)  бәяннән гыйбарәт  булган мәкаләләр  **“рецензия”** дип атала”(3, 108). Ә рәддияне, аның карашынча,  “сәлби тәнкыйтьләргә мөхәррирнең үзе яки башка берәү тарафыннан бирелгән җаваплар” барлыкка китерә. Алга таба бу жанрның рус әдәбият белемендә **антикритика** дип аталуы искәртелә. Авторның рәддия язылу сәбәпләре турындагы хөкемнәре кызыклы. Г. Ибраһимов әдипне кимсетү, шәхесенә тию, абруен төшерү максатыннан язылган рецензияләргә рәддияләр языла дип карый. “Сәхнә хакында, әдәби әсәрләр хакында, әгәр дә шәхси намуска тиелмәгән булса, гадәттә рәддия язылмый. Фәнни әсәрләргә җавап бирелә”(3, 108).  Хезмәт авторы  К.Насыйриның Мәрҗанигә җавабын рәддиягә мисал итеп китерә. 1910 еллар татар әдәби тәнкыйтендә рецензия жанрының активлыгы кими. Ләкин шул ук вакытта рецензия, мәкаләнең

жанр сыйфатларын үзенә алып, аңа тартымлык күрсәтә. Бу тенденция Г.Ибраһимовның тәнкыйть практикасында аеруча калку чагыла.

Г.Ибраһимов тәнкыйди эшчәнлегенең икенче тармагында үз иҗатлары белән милли әдәбиятның яңарышын тәэмин иткән классик әдипләр Г.Тукай, Г.Исхакый, Ф.Әмирхан, Дәрдемәнд, С.Рәмиев, Ш.Камал, М.Фәйзи,Ш.Бабич, Г.Камал, Г.Коләхмәтов һ.б.ларның әсәрләре бәяләнә. Ул "Вакыт", "Йолдыз", "Тормыш","Идел","Кояш", "Аң", "Мәктәп", 1917 елгы Октябрь борылышыннан соң "Эшче", "Кызыл Армия","Татарстан хәбәрләре", "Кызыл Татарстан", "Безнең юл" һ.б. газета-журналларда "Г.Ибраһимов", "Габди", "Галимҗан", "Джан", "Гыйрфанзадә" дигән имзалар һәм "Г.И.", "Г." инициаллары белән актив язышa.

Тәнкыйтьченең бу төр рухи мирасындагы жанрлар системасын аның фикерләү стиле, язмада күтәрелгән актуаль әдәби, фәлсәфи, әхлакый, иҗтимагый-социаль мәсьәләләр, анализ обьектлары һәм принциплары, бәя-хөкемнәренең концептуальлеге билгели. "Әдип үзенең тәнкыйть мәкаләләрендә, - дип яза М.Хәсәнов, - татар әдәбиятының ул вакыттагы гомуми хәле, аерым жанрларның үсеше, әдәби процесста теге яки бу язучының тоткан урыны, татарда сынлы сәнгать, профессиональ музыка туу перспективалары, журналистика һ.б.мәсьәләләргә дә даими рәвештә игътибар итеп килә" (4,532). Аның тәнкыйди мирасында яңа әсәрне әдәбият сөючеләргә тәкъдим итү, аның хакында информация бирүне генә максат иткән кыска, кечкенә күләмле информатив жанрларны табу кыен. Ә теоретик мәсьәләләр, сүз сәнгатенең торышы хакында уйлануларны, әдәби хәрәкәтнең аерым чорын, аның үсеш-үзгәреш закончалыкларын, тенденцияләрен чагылдырган әдәби күзәтү, проблемалы мәкалә, монографик мәкалә, рецензия- мәкалә, монографик рецензия кебек жанрлар Г.Ибраһимов тарафыннан максатчан һәм отышлы файдаланыла. Галим әдәби әсәрләргә бәяне әдәбият-сәнгатькә һәм тәнкыйтькә үзе куйган таләпләр-шартлар, үз сүзләре белән әйткәндә, әсәрнең "төбенә салынган тирән вә кыйммәтле җәүһәрне" укучыга ачып бирү яссылыгында оештыра. Г.Ибраһимов

тәнкыйди эшчәнлегенең асыл хасиятен билгеләп, галим Г.Сәгъди болай дип яза:”... әдип ул вакытта сәнгать әсәрләренең бигрәк эмоция якларына, сәнгатьчә ничек эшләнеп чыгу мәсьәләләренә ныграк кереп, аларга бигрәк шул яктан бәһа бирүдә киң алымлы, зур куәтле тәнкыйтьче иде”(5,18). Д.Заһидуллина тәнкыйтьченең матур әдәбиятны бәяләү принциплары һәм кануннары хакындагы гыйльми-нәзари күзаллауларын түбәндәгечә формалаштыра:”Әдәбият рухи дөньяны чагылдыру максаты куя дигән кагыйдәдән чыгып, Ибраһимов сәнгать әсәре булу өчен тормышны күрсәтү генә җитми, шул тормышның рухын, җанын ачарга кирәк, дип җавап бирә”(6, 7).

Г.Ибраһимовның үткән XX гасыр буенча өйрәнелеп, бүген дә бәхәсле булып калган “Татар шагыйрьләре”(1913) хезмәте **әдәби параллель** жанрында язылган. Дөрес, автор анда С.Рәмиев, Дәрдемәнд, Г.Тукай шигъриятләренә анализны чагыштырма планда үреп алып бармый, ә китапның беренче бүлегендә әдәбият-сәнгать әсәрләрен бәяләүнең яңа принциплары һәм кагыйдәләре нигезендә С.Рәмиев рухи дөньясының идея-эстетик үзенчәлекләрен, шагыйрьлек сыйфатларын ассызыклый да шулар яссылыгында калган ике шагыйрьнең әдәбият мәйданында тоткан урынын, шигъриятләренең хасиятләрен билгели. Әдип татар әдәби тәнкыйтендә поэзияне шәрехләүдә яңа фәнни-теоретик юнәлеш булдыра:”Требуя от художников слова мастерства, гармонии между чувством и его словесным выражением, критик выдвигал на первый план чисто эстетический аспект творчества; приоритет он отдавал таланту, считая его главным критерием для критической оценки. Это в целом выделяло его среди современников. ...В ней Г.Ибрагимов в целом верно и во многом первым вскрыл эстетические заблуждения национальной литературной критики в подходе к поэзии, тем самым объективно послужив становлению новой парагдигмы в татарском литературоведении”(7,174).

Г. Ибраһимов “Хәят”(1911) монорецензиясендә Ф.Әмирхан повестенда романтик иҗат тибы сыйфатларының чагылышын күрсәтеп,

“Мөгаллимә”нең Уфада уйналуы мөнәсәбәте белән”(1915) бәхәсле мәкаләсендә әдәби әсәрдә тормыш дөреслеген гәүдәләндерү принцибын яклап, “Яңа әсәрләр, яңа имзалар вә яшь куәтләр”(1915) күзәтү рецензиясендә Ш.Камал хикәяләре мисалында импрессионизм модернистик агымының тасвирый алымнары һәм чараларының сыналышын ассызыклап, 1910 еллар татар әдәбиятында иҗат юнәлешләренең төрлелеген һәм милли сүз сәнгатенең үсеш перспективасын билгели. “Яңа китап мөнәсәбәте илә”(1912) язмасында иҗтимагый-социаль, әхлакый һәм тормыш-яшәеш мәсьәләләрен характерларның холкы һәм психологиясе аша гәүдәләндерү, “Зур романнар”(1912) рецензиясендә роман , аның жанр хасиятләре, шулай ук башка язмаларда урын алган әдәби типлар, әсәрләрнең милли характеры, тема-мәүзугъ яңалыгы, образлар системасы, вакыйгалар үстерелеше, авторның хикәяләү стиле хакындагы бәя-карашлары галим фәнни-теоретик эзләнүләренең киңкырлы булуы турында сөйли.

Г.Ибраһимовның бай эстетик зәвыгы, сизгер табигате матур әдәбияттагы һәр яңа күренешне тиз тотып ала. “Галиябану хакында бер-ике сүз”(1922) рецензия-мәкаләсендә пьесаны бәяләү уңаеннан халык поэтик иҗаты белән язма әдәбият арасында багланышлар, аларның бер-берсенә йогынтысы, сүз сәнгатенең художестволылыгын камилләштерүдә фольлор казанышларының роле кебек мәсьәләләргә дә игътибар итеә. Мәгълүм булганча, М.Фәйзинең “Галиябану» музыкаль драмасында музыканың идея-эстетик вазифасы үзгәрә, ул очраклы бизәк төсендә генә түгел, ә пьеса эчтәлегенең тукымасын хасил итә. Әсәрнең мәгънәви кисәкләрен бер үзәккә туплаган әдәби деталь буларак кулланыла.. Әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче Г.Ибраһимов әдәби әсәрнең яңа сыйфаты хакында болай дип яза: «Галиябану»ның бөтенләй яңа хасиятләреннән берсе – аның бездә беренче мәртәбә сәхнәгә музыканы, җырны, бер иттифакый зиннәт ясап кына түгел, бәлки төп матди итеп, асыл мөндәриҗә (эчтәлек – Г.Т.) кыйлып кертүедер. Буны «Галиябану» башлап җибәрде. ... Менә шундый хасиятләре белән «Галиябану» бездә ялгыз урында тора, яңа бер баб яки, зуррак тәгъбир булса

да, әйтик, драмалар галәмендә яңа мәктәп ача һәм, шулар аркасында бик хаклы буларак, гаммә алдында иң кадерле урыннарның берсен ала»(8,303).

Г.Ибраһимовның әдәби-эстетик карашлары 1910 еллар татар әдәби тәнкыйтендә мәстәкыйль, үзенчәлекле, әйтергә кирәк вакыты белән каршылыклы үсеш юлы кичерә. Әдипнең кайбер язмаларында галим үзе формалаштырган фәнни мәктәпнең төп кануннары белән генә аңлатып булмый торган берьяклы бәя-хөкемнәре булса да, ул әдәби тәнкыйтьнең фән буларак үсешен тәэмин итүгә, тәнкыйть поэтикасының һәм тарихының мөһим проблемаларын хәл итүгә, әдәби әсәрләрне анализлау-шәрехләүнең яңа парадигмаларын эшләүгә, иҗатның һәр өлкәсендә яшь талантлар тәрбияләүгә үзеннән зур өлеш кертә.

**Әдәбият**

1.Баттал Г.Яңа әсәрләр “Татар шагыйрьләре” //Гыйлаҗев Т.Ш. Рецензияләрдән тәгъзияләргә: XX йөз башы татар әдәби тәнкыйте. – Казан: Татар. кит. нәшр.,2008. – 149 – 154 б.

2.Вәлиди Җ. Матбугат галәмендә// Җамал Вәлиди: әдәби һәм тарихи-документаль җыентык/ төз.Диләрә Абдуллина, Җәүдәт Миңнуллин.- Казан: Җыен, 2010. – 304 – 323б.

3. Г.Ибраһимов. Әдәбият кануннары. Теория словесности. Өченче басма. – Казан: Дәүләт типографиясе, “Сабах”. 1919. – 126б.

4.Хәсәнов М. Г.Ибраһимов – тәнкыйтьче һәм әдәбит галиме// Галимҗан Ибраһимов. Әсәрләр. Сигез томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. – 5 том: Әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хеәмәтләр (1910-1933). – 531-543б.

5.Сәгъди Г. Бездә әдәби тәнкыйть(Үктәбрнең унъеллыгына). – Казан:Татиздат. Безнең юл редакциясе. – 22б.

6.Заһидуллина Д. Язучы, галим, җәмәгать эшлеклесе// Мәгариф. – 2012. - №3. – 5-7 б.

7.Гилазов Т.Ш. Литературная репутация Тукая в эстетической концепции Г.Ибрагимова //Известия ВГПУ – 2009. - №10(44). – С.172-174.

8.Ибраһимов Г. ”Галиябану” хакында бер-ике сүз//// Галимҗан Ибраһимов. Әсәрләр. Сигез томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. – 5 том: Әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хеәмәтләр (1910-1933). – 301-303 б.